ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасы күләмен билгели.

2. Әлеге Закон максатларында "Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында" 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә сәнәгать сәясәте өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән федераль башкарма хакимияте органы яисә сәнәгать тармакларында махсус инвестиция контрактларын төзүгә Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән башка федераль башкарма хакимияте органы тарафыннан Россия Федерациясе исеменнән, шулай ук Россия Федерациясе белән бергә "Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында" 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән махсус инвестиция контракты ягы булып торучы инвесторлар махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар булып таныла.

2 статья. **Салым ставкалары**

1. Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен махсус инвестиция контрактында каралган инвестиция проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә җитештерелгән товарларны реализацияләүдән салым исәп-хисабы буенча беренче табыш алынган салым чорыннан башлап һәм махсус инвестиция контрактының гамәлдә булу срогы тәмамланганчы, ләкин 2025 елдан да соң түгел

(бу елны кертеп), Татарстан Республикасы бюджетына кертелергә тиешле оешмалар табышына салым буенча салым ставкасы 13,5 процент күләмендә билгеләнә.

2. Махсус инвестиция контрактларында катнашучы йөк автотранспорт чараларын җитештерүче оешмалар өчен махсус инвестиция контрактында каралган инвестиция проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә җитештерелгән товарларны реализацияләүдән салым исәп-хисабы буенча беренче табыш алынган салым чорыннан башлап алдагы ун салым чоры дәвамында, ләкин махсус инвестиция контрактының гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң түгел, Татарстан Республикасы бюджетына кертелергә тиешле оешмалар табышына салым буенча салым ставкасы түбәндәгечә билгеләнә:

1) 2025 елга кадәр (бу елны кертеп) – 0 процент;

2) 2026 елдан башлап – 13,5 процент.

3. Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар, махсус инвестиция контрактларында катнашучыларга оешмалар табышына салым буенча киметелгән салым ставкаларын куллану өчен Россия Федерациясе Салым кодексында билгеләнгән шартлар үтәлгән очракта, әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән күләмдәге салым ставкаларын куллана ала.

4. Махсус инвестиция контрактларында катнашучыларга киметелгән салым ставкаларын куллану өчен Россия Федерациясе Салым кодексында билгеләнгән шартлар әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән оешмалар тарафыннан үтәлмәгән очракта, Татарстан Республикасы бюджетына кертелергә тиешле оешмалар табышына салым буенча салым ставкасы әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән оешмалар өчен махсус инвестиция контракты төзелгән чордан башлап алдагы ун салым чоры дәвамында, ләкин махсус инвестиция контрактының гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң түгел, 13,5 процент күләмендә кулланыла.

3 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2017 ел, 02 декабрь
№ 87-ТРЗ